КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 ноябрь г.Казань № 1225

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның социаль яклanган булу дәрәҗәсен арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның 18 яше тулмаган һәр баласына 20 000,0 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның 18 яше тулмаган һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

3. Бер тапкыр бирелә торган түләү башка социаль ярдәм һәм дәүләт социаль ярдәме чаралары күрсәтелгәндә бер тапкыр бирелә торган түләү алучы гаиләләрнең керемнәре составында исәпкә алынмый дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

бер тапкыр бирелә торган түләү бирү эшен оештырырга;

Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасында бер тапкыр бирелә торган түләү турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм әлеге мәгълүмат системаның операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча

идарәсенә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар исемлекләрен төзүне һәм аларны «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә җибәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы тора;

бу карарның гамәле 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 ел, 11 октябрь, 1094 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 16 ноябрь, 1225 нче
карары белән расланды

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның 18 яше тулмаган
һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Бу Тәртип махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның 18 яше тулмаган һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба шул ук эзлеклелектә – бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү, бала) бирү механизмын билгели.

Бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәгеләрнең балаларына бирелә:

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның;

Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче һәм махсус хәрби операциядә катнашучы затларның;

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның;

мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган (махсус хәрби операциядә ирекле катнашу өчен контракт төзелгән) көнне Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны булган, Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең, гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәгән гражданнарның;

граждан мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган (махсус хәрби операциядә ирекле катнашу өчен контракт төзелгән) көнне бала Татарстан Республикасында даими яшәү шарты белән, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган (махсус хәрби операциядә ирекле катнашу өчен контракт төзелгән) көнне Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны булмаган, Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең, гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәгән гражданнарның;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының (Татарстан Республикасындагы эчке эшләр органнарының), Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрелә торган зонага командировка җибәрелгән хезмәткәрләренең.

2. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен баланың законлы вәкиле (алга таба – гариза бирүче) «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең яшәү урыны буенча бүлегенә (алга таба шул ук эзлеклелектә – Үзәк, Үзәк бүлеге) яисә, гариза бирүченең Татарстан Республикасы территориясендә яшәү (тору) урыны булмаган очракта, Үзәкнең Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә кайсы бүлегенә, түбәндәге документларны теркәп, бу

Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында гариза тапшыра:

а) кредит оешмасында гариза бирүчегә ачылган шәхси счет реквизитлары бирелгән документ күчермәләрен;

б) бала тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәләрен;

в) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан билгеләнгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язма ризалык;

г) балага опека билгеләү турында документ күчермәләрен (опекун билгеләнгән очракта);

д) гражданның бу Тәртипнең 1 пунктындагы алтынчы – җиденче абзацларында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә каравын раслый торган документ күчермәләрен;

е) махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның яки Татарстан Республикасы территориясендә баланың даими яшәү фактын раслый торган документ.

Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче шәхесне таныклый торган документын күрсәтә.

Документларның күчермәләре, документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) тарафыннан яки нотариуста таныкланмаса, төп нөсхәләрен күрсәтеп, бер нөсхәдә тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар күчермәләре Үзәккә почта аша җибәрелергә мөмкин. Бу очракта документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) тарафыннан яки нотариуста таныкланган булырга тиеш.

3. Гаризаларны теркәү журналында гаризаны теркәү, әгәр гаризага бу Тәртипнең 2 пункты нигезендә документларның барлык күчермәләре теркәлсә, Үзәк бүлегенә гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Үзәк бүлеге гаризаны һәм документларны аларның барлык кирәкле күчермәләре булу-булмавына һәм билгеләнгән таләпләргә (тиешле рәвештә рәсмиләштерү, документлар күчермәләрендә өстәмә язулар, сызылган сүзләр һәм аларда әйтеп үтелмәгән башка төзәтүләр булмау) туры килү-килмәвенә тикшерә.

Әгәр гариза һәм аңа теркәлә торган документларның күчермәләре бу Тәртипнең 2 пункты таләпләренә туры килмәгән очракта, Үзәк бүлеге хезмәткәре гариза бирүчегә гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу турында хәбәр итә, гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен булган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, гаризаны кабул итүдән баш тартуны язмача рәсмиләштерә һәм шәхси мөрәҗәгать иткән көнне аңа гаризаны документларның теркәлгән күчермәләре белән кире кайтара. Документларның таныкланган күчермәләре теркәлгән гариза почта аша алынганда, Үзәк бүлеге хезмәткәре, гариза Үзәк бүлегенә кергән көннән соң килә торган бер эш көне чykканга кадәр, гариза бирүчегә документларның күчермәләре теркәлгән гаризаны кабул итүдән баш тарту турында язма хәбәрнамә җибәрә.

4. Үзәк бүлеге, документларның дөреслегенә һәм бирелгән белешмәнең дөреслегенә шик барлыкка килгән очракларда, бирелгән вәкаләтләр чикләрендә гариза бирүчеләр тарафыннан бирелгән белешмәне өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

5. Бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча):

гражданнар Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби часте (Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре) шәхси составы исемлекләренә кертелгән яки махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага (алга таба – командировка) җибәрелгән көннән җиде эш көне эчендә Үзәккә бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар исемлекләрен кертә;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 9 статьясы нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның шәхси мәгълүматларын Үзәккә тапшыруга ризалыгын алуны тәэмин итә.

6. Үзәк, Үзәк бүлеге гражданнарның алынган шәхси мәгълүматлары конфиденциальлеген һәм сакланышын тәэмин итә, аларны хокуксыз файдаланган өчен Федераль закон нигезендә җавап бирә.

7. Бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү йә аны билгеләүдән баш тарту турындагы карар Үзәк бүлеге тарафыннан гариза теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Бу Тәртипнең 5 пунктындагы икенче абзацы нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар исемлекләре Үзәккә керми калган очракта, гариза бирүчегә бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы 20 эш көненә озайтыла.

8. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы;

тапшырылган документлардагы (документлар күчермәләрендәге) белешмәнең дөрес булмавы;

бу Тәртипнең 5 пунктындагы икенче абзацы нигезендә бирелә торган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар исемлекләрендә гражданның булмавы;

бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында йә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне баланың бу Тәртипнең 1 пунктындагы өченче – сигезенче абзацларында күрсәтелгән гражданнар категорияләре балаларына карамавы.

9. Гариза бирүчеләрнең кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган түләү суммасын күчерү Үзәк тарафыннан бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә башкарыла.

10. Үзәк квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 ысыннан да соңга калмыйча, һәм ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр, Министрлыкка Татарстан Республикасы бюджетының бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыруга бәйле башкарылган чыгымнары турында хисап тапшыра.

11. Министрлык ел саен, бер тапкыр бирелә торган түләү гамәлгә ашырылган елдан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.

Махсус хәрби операциядә
катнашучы гражданның 18 яше
тулмаган һәр баласына бер тапкыр
бирелә торган акчалата түләүне
гамәлгә ашыру тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең _______________
____________________________ дагы
(шәһәр округы / муниципаль район исеме)
_____ нчы (нче) бүлегенә

Бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында
гариза

Мин, _________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

| Шәхесне таныклый торган документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем биргән | Бирү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ____________________________________________
(индексы, телефоны, электрон почта адресын күрсәтеп,
_____________________________________________________________________________
гариза бирүченең почта адресы)
(гариза бирүченең) индивидуаль шәхси счетның иминләштерү номеры (СНИЛС)
_____________________________________________________________________________ ,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 ел, 16 ноябрь, 1225 нче карары белән расланган Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның 18 яше тулмаган һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның баласына (балаларына) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләүне сорыйм _______________________________
(махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның
_____________________________________________________________________________
бу Тәртипнең 2 пункты нигезендә категориясен күрсәтеп,
_____________________________________________________________________________,
фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда))

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ___________________________________________
(махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның

______________________________________________________________________________,
яшәү урыны адресы)

______________________________________________________________________________;
баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), баланың яшәү урыны адресы)

______________________________________________________________________________;
баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), баланың яшәү урыны адресы)

______________________________________________________________________________
баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), баланың яшәү урыны адресы)

______________________________________________________________________________

Билгеләнгән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне ___________________ ____________________________________________________________________________ да ачылган _____________________________ номерлы шәхси счетка күчерүне сорыйм.

Мәгълүматны, шул исәптән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы мәгълүматны _________________________________
(почта адресы буенча хат,
_________________________________________________________ алырга ризамын.
электрон почта адресы буенча электрон почта белән)

_____________ ____________________________
дата (гариза бирүченең имзасы)

Махсус хәрби операциядә
катнашучы гражданның 18 яше
тулмаган һәр баласына бер тапкыр
бирелә торган акчалата түләүне
гамәлгә ашыру тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

РАСЛЫЙМ

___________________________________
(вазифа исеме)

__________ ________________________
(имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

20__ ел, «__» __________

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар
исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Шәхесне таныклый торган документ мәгълүматлары | Индивидуаль шәхси счетның иминләштерү номеры (СНИЛС) (булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |

Башкаручы ___________________________ _____________ __________
(фамилиясе, инициаллары) (имзасы) (дата)

________________________________